| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ<br>НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН НАРАТБАШ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** Түбән Наратбаш авылы **КАРАР**

«21» май 2025 ел №97-3

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 04 августындагы 416-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлегендә бюджет процессы турында «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 14 июлендәге 54-2 номерлы (12.05.2020 № 90-1, 19.08.2020 № 96-2, 20.10.2020 № 4-3, 15.09.2021 № 28-1, 13.10.2021 № 31-1, 08.04.2022 № 45-1, 18.07.2022 № 52-1, 11.08.2022 № 54-1, 09.03.2023 №68-1, 13.07.2023 №73-1 карарлары ред.) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә::

1.1. 5 статьяның 6 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

«иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында "Электрон бюджет" федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи.».

ундүртенче абзацны шундагыча унбишенче абзац дип санарга.

1.2. 21 статьяда:

түбәндәге эчтәлекле дүртенче һәм бишенче яңа абзацлар өстәргә:

«җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөк транспорт чаралары белән китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләүдән җирле бюджетлар керемнәре;

авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан җирле бюджетлар керемнәре;»;

дүртенче - алтынчы абзацларны шундый ук алтынчы-сигезенче абзацлар дип санарга.

1.3. 23 статьяда:

Унөченче абзацта «паспортлар тапшырыла» сүзләрен «паспортлар (паспортлар проектлары) тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 26 статьяның 3 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта»;

26 статьяның 3 пунктындагы 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агымдагы финанс елында гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондына федераль бюджеттан бирелә торган бюджетара трансфертларның гомуми күләме чикләрендә гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды бюджеты турында закон нигезендә, башкарма хакимиятнең Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыручы федераль органы тәкъдиме нигезендә, Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларының җыелма бюджет язмаларына тиешле үзгәрешләр кертеп,».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы
Р.Н.Шәрәфетдинов